РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«9» апреля 2020 ел

г. Альметьевск

**КАРАР**

№ 470

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2020 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2018 елның 29 гыйнварындагы 136 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2020 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2018 елның 29 гыйнварындагы 136 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 02 августындагы 1101 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 1953 номерлы, 2019 елның 25 апрелендәге 839 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.1. Программа паспортының «Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» дигән 6 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 2 369,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:<br>2018 ел- 1 523,0 мең сум;<br>2019 ел - 423 мең сум;<br>2020 ел- 423 мең сум.<br><br>Искәрмә:* Финанслауның күләмнәре фараз характерына ия һәм, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

1.2. «2018-2020 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны

Зак. № 305-2000

һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа чараларының максатлары, бурычлары һәм финанслау күләме» муниципаль программасы кушымтасында:

- «Терророчылык һәм экстремистлык күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү» дигән 1 бүлекнең 1.20 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.20. Экстремистлыкның криминаль чагылышы актларына комплекслы экспертизаларны финанслау | ТР ӘМР Башкарма комитеты, Әлмәт шәһәр прокуратурасы (килешү буенча) | 2018-2020 | ТР ӘМР бюджеты | 400,0 | 400,0 | 400,0 |

- «Программа буенча барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Программа буенча барлыгы: | | | | 1523,0 | 423,0 | 423,0 |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ